**СОВЕТ МАТЮШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МАТЮШИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

**201 номер** **2019елның«4» декабре**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге составына керүче Матюшино торак пунктындагы гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Матюшино авыл җирлеге составына керүче Матюшино торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге Матюшино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Матюшино торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту..

3. Әлеге карарны Матюшино авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче- Н.И.Миннуллина

Башлык - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы-
Матюшино авыл җирлеге Советы рәисе - Н.И.Миннуллина